ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

Сәламәтлеккә зыян китерә торган тәмәкесез һәм никотинлы башка продукцияне балигъ булмаганнарга сатуга карата тыю билгеләү зарурлыгы турында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Сәламәтлеккә зыян китерә торган тәмәкесез һәм никотинлы башка продукцияне балигъ булмаганнарга сатуга карата тыю билгеләү зарурлыгы турында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатен кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

3. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының күрсәтелгән мөрәҗәгатен хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2019 елның 24 декабре
№ 237-VI ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
2019 елның 24 декабрендәге
237-VI ДС номерлы карарына
кушымта

Сәламәтлеккә зыян китерә торган тәмәкесез һәм никотинлы башка продукцияне балигъ булмаганнарга сатуга карата тыю билгеләү зарурлыгы турында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары яшүсмерләр һәм яшьләр арасында никотинлы чәйни (суыра) торган төрле катнашмаларның, шулай ук вейпларның һәм башкаларның күпләп таралуына борчылалар. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Татарстан Хөкүмәтенә, шулай ук Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гражданнардан тәмәкесез никотинлы продукцияне һәм электрон никотин керту системаларын сатуга карата тыюны законнар югарылыгында билгеләүне үтенгән күпсанлы мөрәҗәгатьләр керә.

Әлеге продукция сәламәтлек өчен куркынычсыз һәм тәмәке тартудан туктаганда никотинга бәйлелектән котылырга ярдәм итә торган чара буларак рекламалана. Әмма бу дөреслеккә туры килми. Бер көчле тәмәкене тартып бетергәндә организмга керә торган никотинның күләме иң күбе 1,5 мг тәшкил итә, ә чәйни (суыра) торган катнашмаларны, шулай ук вейпларны кулланучылар исә, аларны бер тапкыр кулланганда гына да, тәмәке тартучылар белән чагыштырганда, күпкә зуррак доза алалар. Мондый катнашманы суырганда 5 – 10 минут эчендә организмга 20 миллиграммнан күбрәк никотин керә.

Табиблар яшүсмерләрдә һәм яшьләрдә никотинлы тәмәкесез катнашмалар һәм вейплар куллану аркасында хәтерләре һәм хезмәткә сәләтләре начараюны, үзәк нерв системасы, йөрәк-кан тамырлары системаларының һәм эндокрин системаның, ашказаны-эчәклек трактының эше бозылуны, урт һәм теш җитди авырулары барлыкка килүне билгеләп үтәләр. Физик бәйлелеккә өстәп, тагын психологик бәйлелек тиз арта, шул ук вакытта көчлерәк кичерешләргә ихтыяҗ үсә, алга таба ул наркотиклар кулланыга китерергә мөмкин.

Никотинлы продукциянең һәм никотинны тәмәке тартудан үзгә башка ысуллар белән куллану өчен каралган җайланмаларның әйләнеше мәсьәләсе

Европа Бергәлеге һәм Таможня союзы территориясендә законнар белән җайга салынмаган. Таможня союзының «Тәмәке продукциясенә техник регламент»ының гамәлдә булу көче мондый эшләнмәләргә таралмый. Бары тик кайбер җитештерүчеләр генә никотинлы продукцияне куллануның унсигез яшькә җитмәгән затлар өчен чикләнүе турында белешмәне үз ихтыярлары белән язалар.

Яшь буынның сәламәтлеген саклауны тәэмин итү, тәмәкесез никотинлы продукцияне, никотин керту электрон системаларын куллануны һәм таратуны чикләү максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына тәмәкесез никотинлы продукцияне, никотин керту электрон системаларын унсигез яшькә җитмәгән затларга сатуга карата тыю, шулай ук әлеге продукцияне, аны сәүдә объектында тезеп куеп һәм ачык рәвештә күрсәтеп ваклап сатуга карата тыю билгели торган (тәмәкеле продукциягә охшаш рәвештә) федераль закон кабул итүне тизәйтүне сорап мөрәҗәгать итә. Моннан тыш, бу өлкәдә Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә барлыкка килә торган проблемаларны оператив хәл итү максатларында Татарстан парламенты депутатлары Россия Федерациясе субъектларына сәламәтлеккә зыян китерә торган никотинлы һәм башка продукцияне тарату (сату һәм куллану) белән бәйле өстәмә чикләүләрне үз норматив хокукый актлары белән билгеләү хокукын бирү турындагы мәсьәләне карауны сорый.